Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

4 декабрь 2019 ел № 40

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 8 Март ур., з/у 23Б адресы, 16:45:0103:46 кадастор номерлы җир кишәрлегенә карата территорияне ызанлау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 13 декабре 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң бер айдан да ким һәм өч айдан артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Җир кишәрлегенә карата территорияне ызанлау проектын файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуга тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 13 декабренә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга

һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов